КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2023 ел, 5 октябрь

г.Казань

№ 1237

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү дәүләт системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатлар хезмәте өчен түләү һәм адвокатларның түләүсез юридик ярдәм күрсәтү чыгымнарын компенсацияләү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 21 октябрь, 774 нче карары белән расланган Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү дәүләт системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатлар хезмәте өчен түләү һәм адвокатларның түләүсез юридик ярдәм күрсәтү чыгымнарын компенсацияләү тәртибенең 4 нче кушымтасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү дәүләт системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатлар хезмәте өчен түләү һәм адвокатларның түләүсез юридик ярдәм күрсәтү чыгымнарын компенсацияләү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 21 октябрь, 774 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 20 февраль, 103 нче; 2015 ел, 11 март, 144 нче; 2016 ел, 24 март, 164 нче; 2016 ел, 15 август, 563 нче; 2017 ел, 21 февраль, 111 нче; 2017 ел, 7 декабрь, 951 нче; 2019 ел, 20 сентябрь, 858 нче; 2023 ел, 11 март, 239 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Түләүсез юридик ярдәм күрсәтүнең дәүләт системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатлар хезмәте өчен түләү һәм адвокатларның түләүсез

юридик ярдәм күрсәтү чыгымнарын компенсацияләү тәртибенең 4 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта:

түбәндәге эчтәлекле «в[1]» – «в[3]» пунктчалары өстәргә:

«в[1]) Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узучы (узган) гражданнар, Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операциядә катнашу һәм (яки) Россия Федерациясе территориясенә корал белән бәреп керүгә каршы тору бурычларын үтәү шарты белән, Россия Федерациясе Дәүләт чигендә һәм Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операция үткәрү районнарындагы Россия Федерациясе субъектларының чик буенча территорияләрендә кораллы провокация барышында Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләрендә, «Оборона турында» 1996 елның 31 маендагы 61-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 6 пунктында күрсәтелгән хәрби формированиеләрдә һәм органнарда хәрби хезмәттә (хезмәттә) булучы (булган) гражданнар, әлеге территорияләрдә булучы (булган) Россия Федерациясенең хокук саклау органнары хезмәткәрләре (эшчеләре), әлеге территорияләрдә хезмәт һәм башка шундый функцияләр башкаручы (башкарган) гражданнар, шулай ук әлеге гражданнарның гаилә әгъзалары – гражданның Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узуын, яисә Россия Федерациясе милли гвардиясе гаскәрләрендә, «Оборона турында» 1996 елның 31 маендагы 61-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 6 пунктында күрсәтелгән хәрби формированиеләрдә һәм органнарда хәрби хезмәттә (хезмәттә) булуын, яисә Россия Федерациясенең хокук саклау органнарында хезмәттә (эштә) булуын, яисә хезмәт функцияләре һәм башка шуңа охшаш функцияләр башкаруын раслый торган документ, шулай ук:

ире (хатыны) – никахлашу турында таныклык күчермәсен;

ата-аналары (уллыкка алучылар) – әлеге пунктчаның беренче абзацында күрсәтелгән гражданның туу (уллыкка алу) турында таныклык күчермәсен йә әлеге граждан белән туганлыкны раслый торган суд карары күчермәсен;

балигъ булмаган, шул исәптән уллыкка алынган балалар – әлеге пунктчаның беренче абзацында күрсәтелгән гражданның баласы туу (баланы уллыкка алу) турында таныклык күчермәсен йә әлеге граждан белән баланың туганлыгын раслый торган суд карары күчермәсен;

в[2]) Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар, Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операциядә катнашу һәм (яки) Россия Федерациясе территориясенә корал белән бәреп керүгә каршы тору бурычларын үтәү шарты белән, Россия Федерациясе Дәүләт чигендә һәм Украина, Донецк Халык Республикасы, Луганск Халык Республикасы, Запорожье өлкәсе һәм Херсон өлкәсе территорияләрендә махсус хәрби операция үткәрү районнарындагы Россия Федерациясе субъектларының чик буенча территорияләрендә кораллы провокация барышында Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ирекле ярдәм

күрсәтү турында контракт төзегән гражданнар, әлеге территорияләрдә махсус хәрби операциядә катнашу шарты белән Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүгә ярдәм итүче оешма белән контракт төзегән (башка хокукый мөнәсәбәтләрдә булган) гражданнар, шулай ук әлеге гражданнарның гаилә әгъзалары – гражданның Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә мобилизация буенча хәрби хезмәт узуын раслый торган документ, яисә контракт төзүне (Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүгә ярдәм итүче оешма белән башка хокукый мөнәсәбәтләрдә булуны) раслый торган документ, шулай ук:

ире (хатыны) – никахлашу турында таныклык күчермәсен;

ата-аналары (уллыкка алучылар) – әлеге пунктчаның беренче абзацында күрсәтелгән гражданның туу (уллыкка алу) турында таныклык күчермәсен йә әлеге граждан белән туганлыкны раслый торган суд карары күчермәсен;

балигъ булмаган, шул исәптән уллыкка алынган балалар – әлеге пунктчаның беренче абзацында күрсәтелгән гражданның баласы туу (баланы уллыкка алу) турында таныклык күчермәсен йә әлеге граждан белән баланың туганлыгын раслый торган суд карары күчермәсен;

в$^{3}$) Донецк Халык Республикасының, Луганск Халык Республикасының дәүләт хакимияте органнары карарлары нигезендә, 2014 елның 11 маеннан башлап, Донецк Халык Республикасының Кораллы Көчләре, Луганск Халык Республикасы Халык милициясе, хәрби формированиеләр һәм Донецк Халык Республикасы һәм Луганск Халык Республикасы органнары составында хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан затлар, шулай ук әлеге затларның гаилә әгъзалары – хәрби хәрәкәтләрдә катнашуны раслый торган документ, шулай ук:

ире (хатыны) – никахлашу турында таныклык күчермәсен;

ата-аналары (уллыкка алучылар) – әлеге пунктчаның беренче абзацында күрсәтелгән гражданның туу (уллыкка алу) турында таныклык күчермәсен йә әлеге граждан белән туганлыкны раслый торган суд карары күчермәсен;

балигъ булмаган, шул исәптән уллыкка алынган балалар – әлеге пунктчаның беренче абзацында күрсәтелгән гражданның баласы туу (баланы уллыкка алу) турында таныклык күчермәсен йә әлеге граждан белән баланың туганлыгын раслый торган суд карары күчермәсен;»;

«н» – «п» пунктчалары үз көчен югалткан дип танырга.

2. Бу карарның 1 пунктындагы дүртенче – унберенче абзацларының гамәле 2022 елның 24 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин